Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге Екатериновка бистәсендә

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 20 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең Екатериновка бистәсе гражданнар җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда, балачактан инвалидлардан, беренче һәм икенче төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Екатериновка бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Екатериновка бистәсе юлын вак таш япмасы белән ремонтлауга;

3. Әлеге карарны Димтамак авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, **http://pravo.tatarstan.ru** веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Димтамак авыл җирлеге Башлыгы И.А. Сәләмов